# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Торак фондыннан файдалану өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында

Әлеге Закон торак фондыннан һәм аңа бәйле инженерлык коммуникацияләреннән файдалану өлкәсендә барлык милек рәвешләрендәге юридик затларның, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренең һәм гражданнарның административ җаваплылыгын билгели.

### 1 статья. Торак биналарны урынсыз файдалану

Торак биналарны (офислар, кибетләр, складлар итеп) урынсыз файдаланган өчен:

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

### 2 статья. Торак биналарны үзгәртеп җиһазлау яисә яңача планлаштыру

Тиешле тәртиптә рөхсәт алмаган килеш торак биналарны үзгәртеп җиһазлаган яисә яңача планлаштырган өчен:

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

3 статья. Торак биналардан файдалану кагыйдәләрен һәм гомуми кулланылыштагы урыннарның санитар торышы кагыйдәләрен бозу

Торак биналардан файдалану кагыйдәләрен һәм гомуми кулланылыштагы урыннарның санитар торышы кагыйдәләрен бозган өчен:

юридик затларга- хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар житәкчеләренә - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

4 статья. Төзелеш конструкцияләренә техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау кагыйдәләрен һәм нормаларын бозу

Төзелеш конструкцияләренә (фундаментларга, стеналарга, бүлемнәргә, фасад бизәкләренә, балконнарга, козырекларга, лоджияләргә, эркерларга, түшәмәләргә, идәннәргә, түбәләргә, су агып төшү җайланмаларына, тәрәзәләргә һәм ишекләргә, баскычларга, мичләргә) техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау кагыйдәләрен һәм нормаларын бозган өчен:

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар житәкчеләренә хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр штраф салына.

5 статья. Инженерлык җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау кагыйдәләрен һәм нормаларын бозу

Инженерлык җиһазларына (үзәктән җылытуга, кайнар су белән тәэмин итүгә, җилләтүгә, эчке суүткәргечкә һәм канализациягә, газ белән тәэмин итүнең эчке җайланмаларына, чүп ташлагычларга, йорт эчендәге электр челтәренә, электр-, радио- һәм телевидение җиһазларына, лифтларга) техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау кагыйдәләрен һәм нормаларын бозган өчен:

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илле минималь кү-

ләменә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар житәкчеләренә хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр штраф салына.

6 статья. Металлдан куелган детальләрнең торышын тикшереп тору кагыйдәләрен, тулысынча җыелма биналарның ялгау урыннарын герметик ныгыту, конструкцияләрне һәм торбаүткәргечләрне коррозиядән саклау кагыйдәләрен һәм нормаларын бозу

Металлдан куелган детальләрнең торышын тикшереп тору кагыйдәләрен, тулысынча җыелма биналарның ялгау урыннарын герметик ныгыту, конструкцияләрне һәм торбаүткәргечләрне коррозиядән саклау кагыйдәләрен һәм нормаларын бозган өчен:

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар житәкчеләренә хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

7 статья. Биналарда гидроизоляция, тавышны киметү һәм тавыш изоляциясе, киртәләү конструкцияләренең җылылык изоляциясе кагыйдәләрен һәм нормаларын бозу

Биналарда гидроизоляция, тавышны киметү һәм тавыш изоляциясе, киртәләү конструкцияләренең җылылык изоляциясе кагыйдәләрен һәм нормаларын бозган өчен:

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар житәкчеләренә хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

8 статья. Торак йортларны кышкы шартларда файдалануга әзерләү кагыйдәләрен һәм нормаларын бозу

Торак йортларны кышкы шартларда файдалануга әзерләү кагыйдәләрен һәм нормаларын бозган өчен:

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күлә-

менә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

9 статья. Лицензиясез эшчәнлек өчен җаваплылык

Торак фондыннан һәм аңа бәйле инженерлык коммуникацияләреннән файдалану һәм аларны ремонтлау буенча эшчәнлекне билгеләнгән тәртиптә алынган лицензиясез алып барган өчен:

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

10 статья. Торак фондында инженерлык коммуникацияләренә рөхсәтсез тоташтыру

Торак фондында инженерлык коммуникацияләренә рөхсәтсез тоташтырган өчен:

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә - хезмәт өчен түләүнең утыз минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

11 статья. Торак фондын һәм аңа бәйле инженерлык коммуникацияләрен һәлакәт хәленә китергән өчен җаваплылык

Торак фондын һәм аңа бәйле инженерлык коммуникацияләрен һәлакәт хәленә китерерлек гамәлләр кылган яисә һәлакәттән саклыйрлык гамәлләр кылмаган өчен:

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә - хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

52



12 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенен хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрен үтәмәү

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрен үтәмәгән өчен:

юридик затларга - хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр яисә предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә - хезмәт өчен түләүнең унбиш минималь күләменә кадәр, гражданнарга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

13 статья. Торак фондыннан файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау буенча вәкаләтле органнар

Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар хакындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе органнары тарафыннан карала.

Административ штрафлар салына:

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы - Татарстан Республикасының Баш дәүләт торак инспекторы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгының урынбасарлары - Татарстан Республикасының Баш дәүләт торак инспекторының урынбасарлары тарафыннан - хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр;

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең шәһәрләрдәге һәм районнардагы органнары башлыклары - Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекторлары тарафыннан - хезмәт өчен түләүнең сиксән минималь күләменә кадәр.

14 статья. Административ хокук бозулар турында беркетмә

Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмә дәүләт торак инспекторы тарафыннан урында төзелә.

15 статья. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карарга шикаять белдерү

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең урындагы заты тарафыннан чыгарылган административ хокук бозу турындагы эш буенча карарга шикаять административ хокук бозулар хакындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә белдерелә.

Административ хокук бозулар турындагы карарга шикаять белдерү һәм аны кире кагу инспекциянең урындагы затлары тарафыннан куелган хокук бозуларны бетерү буенча таләпләрне үтәү мәҗбүрилеген юкка чыгармый.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 26 марты
N 1101